

«Мәдәният» милли проектынын «Цифрлы мәдәният» тобәк проектын гамәлгә ашыру нәтижәсендә Мордовиядә дvрт виртуаль концерт залы ачылды.
Алар бер ай чамасы элек ачылды һәм классик музыканы яратучыларны кабул итәргә әзер. Виртуаль мәйданчыклар Саранскида 6 нчы балалар музыка мәктәбендә һәм И.Д.Воронин исемендәге Мордовия туган якны ойрәнv музеенын оч филиалында, Инсарда, Ардатовта һәм Темниковта барлыкка килгән. Бу республика халкын туган як чикләреннән чыкмыйча донья музыка сәнгатенә якынайтунын уникаль момкинлеге. Виртуаль концерт залларын булдыру очен заманча мультимедия жиһазлары, шул исәптән экран панельләре, акустик системалар, ноутбуклар һәм микшер пультлары сатып алынган. Болар барысы да югары тизлекле интернет белән бергә артистларнын чыгышларын бозмыйча трансляцияләргә момкинлек бирә. Барлык мәйданчыкларны ачуга тамашачылар чакырылган. Инсарда (рәсемдә) алар 2нче мәктәп укучылары була.
Әйтеп китәргә кирәк, Мордовиядә шулай ук Л.П.Кирюков исемендәге Саранск музыка училищесы, Рузаевка сәнгать мәктәбе базасында, Ковылкино һәм Краснослободск районнарынын Мәдәният vзәкләрендә виртуаль концерт мәйданчыклары эшли.